Ibrahimov, G. G. (2007). *Millət. Tel. Ədəbiiat: Sailanma əsərlər*. [Nation. Language. Literature: Selected Pieces]. 239 p. Kazan, Məgarif. (In Tatar)

Khakimov, B. E. (2005). *Deiatel'nost' Galimdzhana Ibragimova v oblasti tatarskogo iazykoznaniia: avtoref. dis. ... kand. filol. nauk* [The Work of Galimjan Ibragimov in the Field of Tatar Linguistics: Ph. D. Thesis Abstract (Philology)]. Kazan, 29 p. (In Russian)

Khəkimov, B. E. (2002). *G. Ibrahimovnyң "Tatar saryfy" həm khəzerge tatar tel beleme. Galimҗan Ibrahimov həm khəzerge zaman: tuuyna 115 el tuluga bagyshlangan fənni-gaməli konferentsiia materiallary.* ["Tatar morphology" by G. Ibragimov and Modern Tatar Linguistics. Galimjyan Ibragimov and the Present Time: Proceedings of the Scientific Conference Dedicated to His 115th Birthday]. Pp. 262–267. Kazan, Fiker. (In Tatar)

Khəiri, Ə. (2006). *Məkaddimə* [Introduction]. Boryngy Islam mədəniiate, pp. 3–9. Kazan, Rukhi mədəniiat akademiiase. (In Tatar)

Khəsənov, M. Kh. (2002). *Galimҗan Ibrahimov: shəkhese həm iҗaty, ul iashəgən zaman turynda uilanular (tuuyna 115 el tulu uңae belən)* [Galimjyan Ibragimov: Personality and Oeuvre, His Thoughts of His Time (on the 115th Birthday Anniversary)]. Galimҗан Ibrahimov həm khəzerge zaman: tuuyna 115 el tuluga bagyshlangan fənni-gaməli konferentsiia materiallary. Pp. 4–12. Kazan, Fiker. (In Tatar)

Khəsənov, M. Kh. (2010). *Ibrahimov Galimҗan Gyirfan uly. Tatar entsiklopediiase: 6 tomda.* 2 t.: G–I [Ibragimov Galimjyan Gyirfanovich. The Tatar Encyclopedia: in 6 Volumes. V. 2]. Bash mөkhərrir M. Kh. Khəsənov, җavaply mөkhərrir G. S. Sabirҗanov. Pp. 476–477. Kazan, "TR FAнең Tatar entsiklopediia enstituty" dəүlət uchrezhdeniese. (In Tatar)

Miңnegulov, Kh. (2007). *Tatarnyң bөek uly: Məshhyr tatar ədibe G.Ibrahimovnyң tuuyna 120 el* [The Great Tatar Son: The 120th Birthday of the Famous Tatar Writer, G. Ibragimov]. Shəhri Kazan. 16 mart (Ilhamiiat: "Shəhri Kazan" gazetasynyң җomga kushymtasy). (In Tatar)

Zahidullina, D. F. (2000). *Ədəbiiat kanunnary həm zaman (Tatar ədəbiiat nəzariiaseneң barlykka kilүe həm үsesh baskychlary)* [Literary Canon and Time (The Ori-

gin of Tatar Literary Theory and Stages of Its Development)]. 271 p. Kazan, Tatar kit. nәshr. (In Tatar)

Zәkiev, M. Z. (2002). *Galimҗan Ibrahimovnyң tatar tel gyilemenә kertkәn әleshe* [Galimjyan Ibragimov's Contribution to Tatar Linguistics]. Galimҗan Ibrahimov hәm khәzerge zaman: tuuyna 115 el tuluga bagyshlangan fәnni-gamәli konferentsiia materiallary. Pp. 176–185. Kazan, Fiker. (In Tatar)

# Г. ИБРАҺИМОВ – ЯЗУЧЫ, ГАЛИМ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕСЕ

**Таһир Шәмсегали улы Гыйлаҗев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
tgilazov@bk.ru.

Г. Ибраһимов XX гасырның беренче утыз еллыгында татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә тирән эз калдырган татар зыялылары буынының күренекле вәкиле булып тора. XX йөз башы яңарышы тудырган алшартлар һәм милли үсеш ихтыяҗы Г. Ибраһимовны киңкырлы шәхес-иҗатчы итеп тәрбияли. Ул каләме белән татар әдәбиятын яңа сукмакка алып чыгып, үзен мәшһүр сүз остасы, классик язучы итеп таныта. Замандашларыннан үзгә буларак, әдәбиятны гына түгел, ә татар телен өйрәнүне фәнни нигезгә куеп, үз чорының колачлы әдәбият галиме һәм лингвисты буларак шөһрәт казана. Шулай ук Г. Ибраһимовның мирасы әдәби тәнкыйть, Ислам дине, «милли мәгариф һәм педагогика, тәгълим-тәрбия, милли тарих, татар халкының милли-азатлык хәрәкәте һәм иҗтимагый фикер үсеше тарихына, вакытлы матбугат, милли театр, музыка һәм сынлы сәнгать, гомумән рухи тормышның бик күп өлкәләренә карый» [Хәсәнов, 2002, б. 5].

Г. Ибраһимов 1887 елның 28 мартында (яңа стиль белән 12 мартында) Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) Солтанморат авылында Гыйрфан мулла гаиләсендә дөньяга килә. Ул башлангыч белемне гыйлемле, «шактый кырыс холыклы», таләпчән, абруйлы әтисе Гыйрфан мулла һәм, тумышы белән Троицк шәһәреннән булып, заманы өчен яхшы тәрбия алган, укымышлы әнисе Бибихәсәнә абыстайдан ала. Алга таба күрше авылы мәдрәсәсендә һәм үз авылындагы земство мәктәбендә укый. 1898 елда Гыйрфан мулла Галимҗанны, нигездә дин әһелләре әзерләүгә йөз тотып, уку-укытуны традицион формада алып барган Оренбургтагы кадими «Вәлия» мәдрәсәсенә укырга бирә. Анда ул 1906 елга кадәр белем алганнан соң, шәкертләр хәрәкәтендә катнашуы сәбәпле, бу уку йортыннан чыгарыла. Шушы елда Уфада ачылып, татар һәм төрки-мөселман дөньясында иң эре мәгариф, мәдәният учагына әверелгән «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Шәкертлек елларында ук ул казак, кыргыз балаларын укыта һәм әлеге кавемнәрнең һәм башка төрки халыкларның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, теләк-омтылышлары һәм тел-шивәләренең үзенчәлекләре белән якыннан таныша. Дини гыйлемнәр белән бергә дөньяви фәннәр укытылса да, эзләнүчән, зирәк акыллы Галимҗанны «Галия» мәдрәсәсе генә канәгатьләндерми башлый һәм ул, аны калдырып, 1909 елда Казанга килә. Әдәби эшчәнлеге иртәрәк башланган Галимҗан Ибраһимов нәкъ шушы елларда матбугат битләрендә актив языша башлый. 1912 елда Киевка барып чыга, анда мөселман яшьләре, студентлары җәмгыятендә катнаша һәм 1913 елда сәяси эшчәнлеге өчен кулга алына. Төрмәдән азат ителгәч, Казанга кайтып, Г. Тукай, Ф. Әмирханнар белән берлектә Ә. Хәсәни мөхәррирлегендә «әдәби, фәнни. сәяси вә иҗтимагый рәсемле» «Аң» журналын чыгаруны оештырып, аның сәркатибе вазифаларны башкара. 1915 елдан алып 1917 елның февраленә кадәр Г. Ибраһимов – ул мөгаллимлек иткән елларда «үзенә бер иҗади остаханәгә, „әдәбият институты“на әверелгән» [Миңнегулов] «Галия» мәдрәсәсендә укыта.

1917 елның февраленнән алып 1927 елларга кадәрге вакыт аралыгы Г. Ибраһимов гомер юлында актив иҗтимагый-сәяси һәм җәмәгать эшчәнлеге белән характерлана. «1917дә Ф. Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш. Сүнчәләй белән бергә „Ирек“ газетасы чыгара. Татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясен оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсе. Милләт мәҗлесе (1917–1918) һәм Учредительләр җыены депутаты. 1918дә М. Вахитов һәм Ш. Манатов белән бергә РСФСР Милләтләр

эшләре халык комиссариаты каршындагы Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариатын оештыруда катнаша. 1919–1920дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, бер үк вакытта РКП(б) ҮК каршындагы Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе һәм „Кызыл Шәрык“ журналы хезмәткәре. 1920дән ТАССР Мәгариф халык комиссариатында, „Безнең юл“ һәм „Мәгариф“ журналларын оештыручыларның берсе һәм мөхәррире. 1925–27дә Гыйльми Үзәк рәисе, бер үк вакытта „Татарстан төбәкләрен өйрәнү“ бюросы рәисе» [Хәсәнов, 2010, б. 476]. Ә. Хәйри «Борынгы Ислам мәдәнияте»нә язылган сүз башында «әдәбият, мәдәният һәм фән өлкәсендәге күренекле, олы казанышлары өчен Г. Ибраһимовның 1928 елда Дәүләт Сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлануын» һәм «көнчыгышны өйрәнү буенча Бөтенроссия гыйльми ассоциациясенең оештыручы әгъзасы булуын» [Хәйри, б. 4] күрсәтә. Сәламәтлеге какшаган язучы 1927 елда иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән китә һәм үзен фән һәм татар әдәбиятын үстерүгә багышлый. Кызганычка каршы, Г. Ибраһимов та татар халкының зыялылары кебек нахакка гаепләнеп, 1937 елда кулга алына һәм, 1917 елдан үзенең бөтен фикри куәтен һәм рухи егәрлеген багышлаган идеологиянең корбаны булып, 1938 елда Казан төрмәсенең хастаханәсендә дөнья куя.

Г. Ибраһимовның зур каһарманлык белән халкына хезмәт итүгә багышланган гомере әдәби эшчәнлектән башлана. Аның үзе «каләм сынау дәвере» дип атаган чорында язылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909), «Татар хатыны ниләр күрми» (1909, 1 вар.) һ. б. әсәрләрендә, яңа әдәби үрентеләр күренсә дә, нигездә элгәрге традицион тема-проблемалар – уку-укыту, хатын-кыз иреге, шәхес азатлыгы мәсьәләләре яктыртыла. Әдип «Яз башы» (1910), «Сөю-сәгадәт» (1911), «Диңгездә» (1911), «Уты сүнгән җәһәннәм» (1911) һ. б. ларда кеше, аның асылы, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре хакындагы натурфилософик карашлар, яшәүнең әхлакый һәм фәлсәфи нигезе турындагы фикерләр, психологизм кебек сыйфатлар белән татар әдәбиятын баета. Язучының татар тормышын үзгәртү теләк-омтылышларын «аталар» һәм «балалар» тартышы рәвешендә гәүдәләндергән «Яшь йөрәкләр» (1912, басыла 1913) әсәре сүз сәнгатенә күләмле психологик, фәлсәфи роман жанрын алып килүе һәм кеше күңел дөньясын сурәтләүне яңа поэтик алымнар белән баетуы ягыннан игътибарга лаек. Бер якта Зыя, Сабир, Кәрим мәхдүм, Сәлим, Госман, Мәрьям, икенче якта Җәләш мулланың образларын сурәтләп, автор чорның катлаулы картинасын тудыра һәм кешеләр язмышының мохит, тәкъдир, дин-шәригать кануннары белән билгеләнгәнлегенә дә басым ясый. Г. Ибраһимов милли чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерү мөмкинлекләрен киңәйтеп, татар әдәбиятында романтизмның мәйданга килүен тәэмин итә.

Язучының 1913–1917 еллар иҗатында «иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, гади халык тормышы белән бәйләнеш тирәнәя, тарихи темалар яктыртылу, әдәбият-сәнгать, аларның кешелек җәмгятендәге урыны турында уйланулар тагын да калкулана төшә» [Гыйлаҗев, 2007, б. 45]. Татар тормышын психологик, фәлсәфи һәм мәдәни-тарихи планда тасвирлаган әдип аны иҗтимагый-социаль, тарихи яссылыкта сурәтләүгә күчә. «Карт ялчы» (1912), «Көтүчеләр» (1913), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914), «Табигать балалары» (1914) хикәяләрендә гади халык вәкилләренең төрле типлары һәм, элгәрге традицияләргә тугры калып, аларның яшәү фәлсәфәләре яктыртыла. 1905 елгы инкыйлаб, аннан соңгы чор тарихи вакыйгаларын һәм иҗтимагый-милли вәзгыятьне төрле социаль катлам кешеләренең теләк-ниятләре һәм катлаулы язмышлары аша чагылдырган «Безнең көннәр» (1914–1920) тарихи романы язучының алдагы иҗат чорына күпер сала. Автор иҗтимагый-сәяси, социаль азатлык, милләтчелек, халыкчылык, инсаниятчелек, кадимчелек һәм җәдитчелек, шәкертләр хәрәкәтләрен сурәтләп, берьяктан милли чынбарлыкның киң панорамасын, икенче яктан татарларның Россия тарихында мәгълүм роль уйнауларын күрсәтүгә ирешә. Әсәрнең һәрберсенә әдәби-эстетик вазифа йөкләнгән образлары: революционерлар (Зариф Булатов, Давыт Урманов, Хәбиб Мансуров, Баязит Карый), шәкертләр (Җиһангир, Сөләйман), приказчиклар (Фәхри, Габдрахман), татар хатын-кызлары (Нәфисә, Гөлбикә, Һаҗәр; Разия Ширинская, Гәүһәр) һ. б. шәхес иреге, милли яңарыш өчен көрәштә һәм сәяси хәрәкәттә фикер үзгәрешен һәм үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлау ягыннан яңалык алып килә.

Хосусый үзенчәлекләргә ия булып, төбәк әдәбияты төсендә яшәгән татар әдәбияты 1917

елгы Октябрь борылышыннан соң, эчке әдәби багланышлар көчәеп, СССР халыклары әдәбиятының бер өлеше буларак үсә башлый. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920), «Кызыл чәчәкләр» (1921) һәм «Тирән тамырлар» (1928) әсәрләрендә революцион вакыйгалар, гражданнар сугышы һәм күмәк хуҗалык оештыру фаҗигаләре һәм аларның рухка һәм үзаңга, үзара мөнәсәбәтләргә йогынтысы кешеләрнең катлаулы язмышы аша күрсәтелә. Совет әдәбиятының уртак идеалын, ягъни иҗтимагый-социаль азатлыкка ирешү мәсьәләсен яктырткан «Кызыл чәчәкләр» повестенда, төрле социаль катлам – рухани, сәүдәгәр, урта һәм ярлы крестьян балалары булуга карамастан, биш дус булып үскән Фазыл, Гали, Гыйлаҗи, Шаһбаз, Солтанны революция дулкыннары төрле сукмакларга аерып, бер-берсенә каршы куя. Автор тарафыннан революция, сыйнфый көрәш кенә татар милләтен якты киләчәккә алып килә дигән фикер үткәрелә.

Г. Ибраһимовның бу чор иҗатында, социалистик реализм агымының тар сукмакларыннан бармыйча, тема, рух һәм аһәң белән аерылып торган әсәрләр дә иҗат ителә. Татар халкының милли традицияләрен, сабантуй бәйрәмнәрен, матур гореф-гадәтләрен, менталитетын сәнгатьчә гәүдәләндергән «Алмачуар» (1922), казак-кыргыз кавеменең тормышын милли-этнографик яктан гына түгел, икътисадый һәм иҗтимагый яктан да тулы тасвирлаган «Казак кызы» (1924), Идел буе ачлык вакыйгаларын, аның куркыныч, фаҗигале битләрен натуралистик алымнар ярдәмендә сурәтләгән «Адәмнәр» (1923) повесте Г. Ибраһимовның эзләнүчән, яңалыкка омтылучан һәм киң колачлы язучы икәнлеген раслый.

Г. Ибраһимов – татар әдәбият белеменең төрле тармаклары – әдәбият тарихы, әдәбият теориясе һәм тәнкыйте формалашуы һәм үсешендә зур роль уйнаган шәхесләрнең берсе. Ул әдәби тәнкыйть белән, аның эзләнүләр чорын үтеп, камилләшү-җитди сыйфади үзгәрешләр кичерә башлаган 1910-елларында шөгыльләнә башлый һәм тиз арада киң карашлы, теоретик әзерлекле, талантлы һәм үзенчәлекле тәнкыйтьче буларак таныла. Г. Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлеген ике юнәлештә алып бара: 1) әдәби тәнкыйтьнең поэтикасы һәм тарихы мәсьәләләре; 2) әдәбият мәйданында урын алган әдәби әсәрләргә чорның гыйльми-нәзари, әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи фикерләре ирешкән казанышлары ноктасыннан бәя бирү, үз заманының әдәби процесс үзенчәлекләрен ачу. Галим әдәби тәнкыйть поэтикасының нәзари төшенчәләрен һәм кагыйдәләрен аңлауга һәм үзләштерүгә, шәркый традицияләрне инкарь итмәсә дә, гареб-рус әдәбиятлары ирешкән казанышлар ноктасыннан якын килә. Аның эшчәнлегендә тәнкыйтьнең предметы, термины, әдәби әсәрне бәяләү принциплары һәм методлары, төрләре һәм жанрлары мәсьәләләре карала. Г. Ибраһимовның төрле еллардагы язмаларында чагыла килгән нәзари карашлары «Әдәбият дәресләре» (1916) китабында фәнни нигезгә утыртылып, гыйльми концепция рәвешен ала. Мәсәлән, ул тәнкыйть сүзенең килеп чыгышы, мәгънәсе, фәнни һәм гамәли әйләнешкә керүе турында уйлана: «Тәнкыйть сүзе „нәкыд“ матдәсеннән алынган. Лөгать мәгънәсе акчаның чынын сахтәсеннән (ялганыннан. – *Т. Г.*) аеру димәктер» [Ибраһимов, 1919, б. 106]. Әдәби тәнкыйтьнең юнәлеше һәм әсәргә бирелгән бәя ягыннан «иҗаби» (уңай. – *Т. Г.*) һәм «сәлби» (кире. – *Т. Г.*) төрләрен, рецензия, мәкалә, рәддия жанрларын билгели.

Г. Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегенең икенче тармагында үз иҗатлары белән милли әдәбиятның яңарышын тәэмин иткән классик әдипләр Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Камал, М. Фәйзи, Ш. Бабич, Г. Камал, Г. Коләхмәтов һ. б.ларның әсәрләре бәяләнә. Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» (1913) китабында шигырь (әдәбият) – шагыйрь – җәмгыять буынын, талант һәм матурлык эстетикасы кануннары яссылыгында карап, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Г. Тукайлар рухи дөньясының идея-эстетик үзенчәлекләрен, шагыйрьлек сыйфатларын билгели. Әдип татар әдәби тәнкыйтендә поэзияне шәрехләүнең яңа фәнни-теоретик юнәлешен булдыра. Хезмәттәге әдәбият турындагы нәзари карашлар, шигъриятне бәяләүнең яңа кагыйдәләре татар галәмендә тәнкыйтьнең романтик юнәлеше барлыкка килү хакында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Г. Ибраһимов «Хәят» (1911) монорецензиясендә Ф. Әмирхан повестенда романтик иҗат тибы сыйфатларының чагылышын күрсәтеп, «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» (1915) бәхәсле мәкаләсендә әдәби әсәрдә тормыш дөреслеген гәүдәләндерү принцибын яклап, «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр» (1915) күзәтү рецензиясендә Ш. Камал хикәяләре мисалында импрессионизм

модернистик агымының тасвирый алымнары һәм чараларының сыналышын ассызыклап, 1910 еллар татар әдәбиятында иҗат юнәлешләренең төрлелеге һәм милли сүз сәнгатенең үсеш перспективасын билгели. Тәнкыйтьченең бай эстетик зәвыгы, сизгер табигате матур әдәбияттагы һәр яңа күренешне тиз тотып ала. «Галиябану хакында бер-ике сүз» (1922) рецензия-мәкаләсендә пьесаны бәяләү уңаеннан халык поэтик иҗаты белән язма әдәбият арасында багланышлар, аларның бер-берсенә йогынтысы, сүз сәнгатенең художестволылыгын камилләштерүдә фольклор казанышларының, бу әсәргә нисбәтле җыр, музыканың роле кебек мәсьәләләргә дә игътибар ителә. «<...>. Менә шундый хасиятләре белән „Галиябану“ бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб яки, зуррак тәгъбир булса да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала» [Ибраһимов, 1978, б. 303]. Язучылардан хис һәм форма, сурәт берлеген таләп иткән тәнкыйьче әдәби әсәрне бәяләүдә эстетик аспектны беренче урынга куя, татар әдәби тәнкыйте белемен яңа әдәби-теоретик парадигмалар белән баета.

Әдәбият белеменең әдәбият теориясе һәм тарихы кебек тармакларының мөстәкыйль үсеш сукмагына чыгулары Г. Ибраһимов исеме белән дә бәйләнгән. Галимнең әдәбият, аның асылы хакындагы теоретик карашлары 1910 елларда дөнья күргән язмаларында урын ала башлый. «Әдәбият мәсьәләләре» (1910) мәкаләсендә ул, нәсер һәм нәзым төшенчәләренә игътибар итеп, сүз сәнгате әсәрләренең тезмә һәм чәчмә формаларда язылуын, әдәбиятның укучы хисенә йогынты ясап, билгеле бер фикергә алып килүен күрсәтә. Алга таба әдәбиятта үгет-нәсыйхәт, дидактизмны кире кагып, укучы хисенә һәм хыялына тәэсир иткән образлылык аша матурлык эстетик категориясе турында сүз алып бара. Шуның белән Г. Ибраһимовның әдәбият хакында яңа концепциясе формалаша башлый. Шигырь төшенчәсен матур әдәбият мәгънәсендә аңлаган Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» китабында әдәбиятка түбәндәге билгеләмәне бирә: «Безнең рух вә хыялымызга тәэсир итәчәк, хиссиятемезне, тәэссоратымызны кузгатачак һәрбер нәрсә – шигырь. Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа» [Шунда ук, б. 81]. «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» (1915) мәкаләсендә дә әдәбият һәм сәнгать хакындагы гыйльми карашлар шушы юнәлештә үстерелә. Д. Заһидуллина XX гасыр башы теоретик фикерендә барлыкка килгән яңа әдәби мәктәпнең Г. Ибраһимов тарафыннан нигезләнүен ассызыклый: «Төп законны, мәктәп хасил итәрлек үзәк кагыйдәне Г. Ибраһимов тәкъдим итә һәм аны „Татар шагыйрьләре“ китабында нәзари яктан нигезли» [Заһидуллина, б. 208]. Әдәбиятның асыл хасиятләреннән миллилек, халыкчанлык һәм башка мөһим әдәби күренешләр дә шушы концепция кысаларында үзләштерелә.

Галимнең «Галия» мәдрәсәсендә татар әдәбиятын укыту тәҗрибәсен һәм нәзари карашларын гомумиләштерү рәвешендә язылган «Әдәбият дәресләре» (1916) китабында әдәби әсәрнең фәнни концепциясе тәкъдим ителә. Галим эчтәлек һәм форманың диалектик бәйләнешен таныган хәлдә, идея әсәрнең формасын, һәр төзелеш элементы сайланышын тәэмин итә дигән караштә тора. Шулай ук ул милли әдәбиятта төр һәм жанрларны, аларның хосусиятләрен билгели; сурәт-характер-тип нәзари төшенчәләрен өйрәнеп, аларны әсәрнең сәнгатьчәлеген характерлаучы эстетик категорияләр буларак бәяли.

Ул әдәбият фәнендә үзен көчле теоретик буларак кына түгел, ә гамәл кешесе, үз нәзари карашларын, концепцияләрен практикада куллану, фәнни табышларын нәтиҗәле тормышка ашыручы итеп тә күрсәтә. Татар әдәбиятын мәктәптә укыту мәсьәләре, аның методикасы галимнең «Яңа әдәбият. Дәреслек» (1914, 1919, 1920), «Әдәбият дәресләре» (1916) әсбапларында карала.

Г. Ибраһимов Октябрь борылышыннан соң да бу өлкәләрдә гыйльми эшчәнлеген дәвам иттерә. Галимнең әдәби-эстетик һәм нәзари карашлары, илдәге кискен иҗтимагый-рухи һәм икътисадый үзгәрешләр тәэсирендә трансформацияләнә. Ул бу чорда әдәбиятны, аның асылын бәяләү һәм тикшерүнең марксизм классикларының сүз сәнгате һәм мәдәният хакындагы өйрәтүләренә нигезләнгән яңа методологиясен эшләүчеләрнең берсе була. Аның «Татар әдәбиятында өченче дәвер. Аңларга тырышыгыз!)» (1922), «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» (1922), «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» (1924) һ. б. хезмәтләрендә, марксистик-ленинчыл әдәбият белеме принциплары ныгытылып, әдәби мираска

мөнәсәбәт, аны шәрехләү, совет чорында әдәбиятны үстерү һ. б мәсьәләләр карала.

Г. Ибраһимов – татар тел гыйлеме, аның төрле тармакларының үсешенә дә зур өлеш керткән шәхесләрдән. Ул, мәктәп-мәдрәсәләрдә татар теленнән уку дәреслеге буларак файдаланылып, 1917 елга кадәр берничә мәртәбә басылган «Татар сарыфы» (1911, 1913 һ. б.) һәм «Татар нәхүе» (1911, 1914 һ.б.) кебек фундаменталь хезмәтләрен яза. Аларда татар теле грамматикасының теориясе һәм аларны өйрәнүнең методологиясе эшләнә. «Бу бөек язучы, публицист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесенең мирасы татарларда һәм башка төрки халыкларда гуманитар белемнәр үсеше өчен зур кыймммәткә ия. Ул хәзерге татар тел гыйлеме методологиясен эшләүдә һәм аның чын мәгънәсендә фәнни дисциплина буларак формалашуында зур роль уйный» (сүзгә сүз тәрҗ. – *Т. Г.*) [Хакимов, 2005, с. 3], – дип ассызыклый Б. Хәкимов.

«Татар сарыфы»нда Г. Ибраһимов, XX гасыр башында кулланылышта булган дәреслекләрдән аермалы буларак, фәнни нигезгә утыртылган һәм татар теленең төзелешенә туры килгән хезмәт язуны максат итеп куя: «Минем бөтен мәнбәгым (чыганагым. – *Т. Г.*) – саф татар теле булды. Кулымнан килгән чаклы, телемезнең эченә, төбе вә рухына керергә, андагы хасият вә мөнәсәбәтләрне табарга вә шундан ала алган нәтиҗәне мәйданга куярга тырыштым. Һич булмаса, өмидем, ниятем шул булды» [Ибраһимов, 2003, б. 12]. Әлеге хезмәттә авторның төп игътибары татар теленең сүз төркемнәре системасын тикшерүгә юнәлтелеп, аларны классификацияләүдә семантик һәм морфологик принципларны нигез итеп алуы галимнең лингвистик мирасын өйрәнүчеләр тарафыннан ассызыклана. Г. Ибраһимов «сүз төрләре» терминына мөрәҗәгать итеп, татар теленең *исем, сыйфат, сан, фигыль, кушымта, алмаш, каед, ярдәмлек, ымлык* төркемнәрен күрсәтә. Бу бүленештә, җөмләдә сүзләр бәйләнешен, мәгънә мөнәсбәтәтләрен белдерүгә хезмәт иткән *кушымтаны* искә алмаганда, хезмәт авторы аерып чыгарган, мөстәкыйль сүз төркемнәре, аларның морфологик сыйфатлары, төп үзенчәлекләре хәзерге татар тел системасына туры килә, ә «ярдәмлек сүз төркемнәренә килгәндә исә, аларны өйрәнүдә тикшерелгән хезмәттә теоретик нигез дә, системалылык та әле урнашып җитмәгән һәм аларның классификациясе хәзергедән нык аерыла» [Хәкимов, 2006, б. 266].

Аерым синтаксик берәмлекләр һәм аларның функцияләрен билгеләүдә гарәп һәм рус телләренең йогынтысы сизелсә дә, Г. Ибраһимовның «Татар нәхүе» китабы татар теленең синтаксик төзелешен фәнни нигезгә утыртуда зур роль уйный. Галим *баш* (ия, хәбәр) һәм *иярчен* (тәмамлык, аергыч, хәл (урын, вакыт, сәбәп, рәвеш) кисәкләрен аерып чыгара. Хезмәт авторы тиңдәш кисәкләрне, кушма җөмләләрне һәм иярчен җөмлә типларын да тикшереп, синтетик чаралар ярдәмендә барлыкка килгән конструкцияне генә иярчен җөмлә буларак карый. Ул татар тел белемендә беренчеләрдән буларак, *тезем* синтаксик берәмлеген күрсәтә һәм аның хасиятләрен билгели.

Б. Хәкимовның Г. Ибраһимов эшчәнлеге тикшерелгән хезмәтендә аның лингвистик терминологияне формалаштыруга керткән өлеше төрле аспектларда бәяләнә: «Галим терминология өлкәсендә эшчәнлеген ике юнәлештә алып бара: 1) татар теленең фәнни терминологиясен булдыруның теоретик нигезен һәм принципларын эшләү; 2) татар теленең фәнни, иң беренче чиратта лингвистик терминологиясен эшләүдә турыдан-туры катнашу» (тәрҗ. – *Т. Г.*) [Хакимов, 2005, с. 32]. Фәнни хезмәтләрендә файдаланылган терминнарның генетик пластларын аерып чыгару һәм ул файдаланган терминнар ясалыш юлларын анализлау аша Г. Ибраһимовның хәзерге татар теле лингвистик терминологиясенә нигез салуы ассызыклана. Болардан тыш галимнең орфоэпия һәм телне мәктәп-мәдрәсәләрдә өйрәнү, балаларга җиткерү юллары һәм ысуллары мәсьәләләрен яктырткан «Татар имлясы: Мәктәпләр өчен дәреслек» (1914), «Татар телен ничек укытырга (телебезнең методикасы хакында бер тәҗрибә» (1916), «Тел сабаклары. 1–2 нче китап» (1918) һ.б. кулланмалары дөнья күрә. Ана телен татар әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә укыту принцибы Г. Ибраһимов методикасының үзенчәлеге булып тора. Бу предметларны өйрәнүнең максаты татар халкын мәдәниләштерү, милли үсеш, яшь буынны милли рухта тәрбияләп, аны инкыйраздан саклап калу белән билгеләнә. Акад. М. З. Зәкиев: «Г. Ибраһимов киңкырлы лингвист булуы һәм лингвистиканы иҗтимагый тормышның актуаль проблемаларына органик бәйли алуы белән хәзерге тел галимнәренә үрнәк булып тора. Аның бөеклеге, тел гыйлеме өлкәсендә дә классик булуы менә шуның белән

аңлатыла да инде» [Зәкиев, б. 184 ], – дип яза. Болардан тыш галим татар халкы тарихы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә тел тарихы («Без татарбыз», 1911), төрки әдәби телләр үсеше («Телләре башка булса да, күңелләре бер», 1916 һ. б.) проблемаларын да өйрәнеп, аларны объектив һәм тарихи аспектта хәл итәргә омтыла.

Г. Ибраһимовның мирасында татар халкы тарихын, иҗтимагый-сәяси, милли азатлык һәм мәгърифәтчелек хәрәкәтләрен, аларның үсеш баскычларын, милли мәдәният үзенчәлекләрен яктырткан, күренекле шәхесләрнең иҗтимагый-милли кыйммәтен бәяләгән хезмәтләр, мәкаләләр бар. «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» (1922), «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре, 1905» (1925), «Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» (1919), «Каюм бабаның йөз еллыгы» (1926), «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» (1927), һ. б.лар шундыйлардан. Яңа сыйнфый-тарихи шартларда иҗат һәм фәнни эшчәнлекнең һәр төрендә социологик концепция ныклап урнашуга карамастан, публицист Г.Ибраһимов соңгы язмада теле, үзгә тарихи язмышы, тормышы, гореф-гадәтләре булган татар халкының «мәдәнияте үзенең милли нигезендә, үз ана телендә үз тормышының аерым хасиятләре белән сугарылыр, аерым рәвешләнер» [Ибраһимов, 2007, б. 222] дип, аның миллилеген саклаган хәлдә үсеш перспективасын яклый.

Җиде буын бабасы муллалар нәселеннән булган Г. Ибраһимовны фикри һәм иҗади эзләнүләр чорында дин тарихы, мәдәният мәсьәләләре кызыксындыра. Аның Ислам динен өйрәнү фәненә зур өлеш керткән ике китабы – төрек теленнән тәрҗемә ителгән «Хакыйкате Исламия», тарихи чыганакларга таянып язылган «Борынгы Ислам мәдәнияте» монографиясе 1909 елда Оренбургта басылып чыга. Хезмәт авторы бай фактик материалларга һәм мәгълүматларга нигезләнеп, Ислам мәдәниятенең барлыкка килү, үсеш баскычлары һәм дөнья мәдәнияте тарихында аның тоткан урыны турында тирән гомумиләштерүләр ясый. Ә. Хәйри әлеге хезмәт белән Г. Ибраһимовның «үзен бик тирән фикер йөртүче акыл иясе итеп танытуын» [Хәйри, б. 9] күрсәтә. Гарәпләрнең Ислам мәдәниятенә кадәрге җаһилият чорында гыйлем, мәдәнияткә сәләтлелек булса да, шартлар табылмау сәбәпле, мәҗүсилек, күпаллалык, наданлык, әхлаксызлык хөкем сөрү билгеләнә. Шул ук вакытта бу кавемнең Корьәнне кабул итү һәм тәкъдир итү өчен, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән шигырь, сүз сөйләү осталыгы, ягъни ортаторлык сәнгатенең үскәнлеге искәртелә.

Ү гасыр ахырына таба тынычлык югалып, гарәпләрдә «уяну», тарихчылар «гарәп яңарышы» дип исемләгән чор башлана. Шушы яңарыш заманында Мөхәммәд галәйһис-сәлам бу кавемне Ислам диненә өнди башлый. Шушы чордан җаһилият бетеп, Исламият дәвере башлана. Хезмәт авторы тарафыннан бу вакыйга дөнья күләм тарихи, мәдәни яссылыкта бәяләнә: «Гарәп эченә хәтта бөтенләй тиңе булмаган бер „инкыйлаб дәвере“ керә. Дөньябызның сәяси, дини, гыйльми, әдәби, әхлакый булган бик бөек вә гадәттән тыш инкыйлабының „баш хәрәкәте“ башлана» [Ибраһимов, 2006, б. 28]. Г. Ибраһимов Мөхәммәд галәйһис-сәлам тормышы һәм аның сыйфатлары, Ислам хакларын урнаштыруда каршылыклар, аның Мәккәдән Мәдинәгә күчүе һәм ирешкән казанышлары хакында җентекле сөйли. Аллаһының ярдәменә таянып, бу бөек затның мәдәни әхлак, чын инану, кешелеккә яраклы гамәл, хокук, хөррият бирүе, тигезлек һәм гаделлек урнаштыруы әйтелә. Алга таба Мөхәммәд галәйһис-сәлам вафат булгач, аның сәхабәләре, хәлифәләр Әбүбәкер разый Аллаһу ганһе, хәзрәти Гомәр, хәзрәти Гали һ. б. лар чорында мөселманнарның гомуми тарихы, Ислам мәмләкәтенең территориаль яктан үсү-зураюы бәян ителә. Яулап алу, басып алу сугышлары тәмамлангач, мәдәниләштерү процессы башланып, Ислам йортына гыйлем, фән, фәлсәфә кертүдәге нәтиҗәле гамәлләр асызыклана.

Г. Ибраһимов Мөселман дөньясында гыйлемнәрнең тармаклануын билгели. Корьән аятьләре тупланып, исламият төрле халыклар арасында таралганнан соң, төрле мәзһәб, фикер, фәтва күбәю дини һәм гарәп теле белемнәре, ягъни «голүм хасса» бүлеге барлыкка килүгә сәбәп була. Ә инде гомумкешелеккә караган математика, табигать белемнәре, әхлак-әдәп турындагы гыйлемнәр «голүм гыйлем»не тудыра. Грек, фарсы, һинд милләтләреннән төрле фән китаплары тәрҗемәләр ителү һәм бу эшчәнлек тәэсирендә фән һәм гыйлемнең иҗади үстерелү баскычлары аерып чыгарыла. Мәсәлән, автор тарихи чыганакларга таянып, фән һәм гыйлемнең биш йөз тармакка бүленгәнлеген күрсәтә. Алга таба Ислам мәдәнияте үсешенең күрсәткечләре булган, маристаннар (хастаханәләр. – *Т. Г.*), китапханә-

ләр, әдәбият, музыка, шәһәрләр хакында киң мәгълүмат бирә. Автор: «Гыйлем <...> аларны тарихта бөек дәрәҗәгә күтәрде. Шул заманның һәр яктан алда булган халкын ясады. Урта гасырларның хөрмәт таҗын аларга биреп, хөрмәт баскычының иң югарысына менгерде. Аларны галәмгә остаз итте» [Шунда ук, б. 160], – дип яза. Ислам дөньясында тудырылган мөселман мәдәнияте Аурова мәдәниятенең нигезе булып тора. Заманнар үтү белән, «мәдәният гыйлеме» кояшы мөселман дөньясында бата һәм ул Ауропада чыгып, аны нурландыра башлый.

Галимҗан Ибраһимов әдәби мәктәбендә тәрбияләнгән күпләгән татар язучылары бүген дә аның әдәби һәм поэтик традицияләрен дәвам итәләр. Язучының рухи мирасы шулай ук төрки-тугандаш халыкларның сүз сәнгать-ләренә, әдәбият белеме һәм тел гыйлемнәренә зур йогынтысы ясый. Аның аерым әсәрләре рус һәм кайберләре төрки телләргә тәрҗемә ителгән. «Г. Ибраһимовны тугандаш халык-ларның Б. Кербабаев (төрекмән), С. Муканов (казах), С. Айни (таҗик), Д. Юлтый (башкорт) кебек мәшһүр каләм ияләре югары бәялиләр, аның шифалы йогынтысын кат-кат искәртәләр. <...> Әзәрҗайҗан әдәбиятының классик язучы-сы Самәд Вургун болай ди: „Сезнең Галимҗан татарның гына түгел, бөтен Шәрык халык-ларының да бөек әдибе ул“» [Миңнегулов].

Тел, әдәбият белемнәре, халык авыз иҗаты, сәнгатьнең төрле өлкәләре буенча эре академик һәм гыйльми фәнни-тикшерену үзәге булган Татарстан Республикасы Фәннәр Академия-сенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (1996 елга кадәр Тел, әдәбият һәм тарих институты) 1967 елдан Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә.

Татар халкының күренекле галиме, уникаль шәхесе Г. Ибраһимов, нинди генә шартларга куелуга карамастан, милләтенең әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерү юлыннан читкә тайпылмый, туган халкына булган тирән ышанычы һәм мәхәббәте аңа көч бирә. Аның әдәби әсәрләре һәм гыйльми хезмәтләре милли мәдәниятне, сәнгатьне һәм татар фәнен үстергә зур өлеш кертсә, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге татар халкының рухи тормышында һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихында тирән эз калдыра.

**Әдәбият**

*Гыйлаҗев Т. Ш.* Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. Казан: Мәгариф, 2007. 239 б.

*Гыйлаҗев Т. Ш.* Г. Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйтен формалаштыру һәм үстерүдәге роле (1910 еллар тәнкыйте мисалында) // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан, 2012. Б. 56–59.

*Ибраһимов Г.* Борынгы Ислам мәдәнияте. Казан: Рухи мәдәният академиясе, 2006. 215 б.

*Ибраһимов Г.* Әдәбият кануннары. Теория словесности. Өченче басма. Казан: Дәүләт типографиясе, «Сабах». 1919. 126 б.

*Ибраһимов Г.* Татар сарыфы. Казан, 2003. 119 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 том: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 615 б.

*Ибраһимов Г. Г.* Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2007. 239 б.

*Заһидуллина Д. Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Зәкиев М. З.* Галимҗан Ибраһимовның татар тел гыйлеменә керткән өлеше // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 176–185.

*Миңнегулов Х.* Татарның бөек улы: Мәшһүр татар әдибе Г. Ибраһимовның тууына 120 ел // Шәһри Казан. 2007. 16 март (Илһамият: «Шәһри Казан» газетасының җомга кушымтасы).

*Хәкимов Б. Э.* Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы» һәм хәзерге татар тел белеме // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 262–267.

*Хәйри Ә.* Мөкаддимә // Борынгы Ислам мәдәнияте. Казан: Рухи мәдәният академиясе, 2006. Б. 3–9.

*Хәсәнов М. Х.* Галимҗан Ибраһимов: шәхесе һәм иҗаты, ул яшәгән заман турында уйланулар (тууына 115 ел тулу уңае белән) // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 4–12 б.

*Хәсәнов М. Х.* Ибраһимов Галимҗан Гыйрфан улы // Татар энциклопедиясе: 6 томда. 2 т.: Г–Й / Баш мөхәррир М. Х. Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г. С. Сабирҗанов. Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедия энституты» дәүләт учреждениесе, 2010. Б. 476–477.

*Хакимов Б. Э.* Деятельность Галимджана Ибрагимова в области татарского языкознания: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.